# Ветеран тормышы
*№2 (87)*

# Без дә читтә калмыйбыз



2нче санлы гимназиядә

Билгеле булуынча, 2025 ел Русия Президенты Указы белән Ватанны саклаучылар елы дип, ә Башкортстан Башлыгы Указы белән Махсус хәрби операциядә катнашучыларга һәм аларның гаиләләренә ярдәм итү елы дип игълан ителде. Бу уңайдан район мәдәният йортында бик матур чара да оештырылды.

Район ветераннары бу фәрманнарны бик хуплап каршы алдылар һәм актив кушылдылар да. Хезмәт, сугыш, Кораллы Көчләр һәм хокук саклау органнары ветераннары яшьләр, укучы балалар белән хәрби-патриотик темаларга очрашулар, әңгәмәләр үткәрәләр, сорауларга җаваплар бирәләр. Бу эштә бигрәк тә Борай 2нче санлы гимназиясе, район китапханәсе, Бадрак, Каенлык, Кәшкәләү, Чалкак авыл белеме бирү учреждениеләре активлык күрсәтә.

Махсус хәрби операциядә катнашучы якташларыбызга ярдәм итүдә дә ветераннар читтә калмый. Маскировкалау челтәре үрүдә, аның өчен материал алырга акча җыюда да пенсионерлар үзләренең өлешләрен кертәләр.